| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

03.03.2021 № 172

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларының яңа редакциясен раслау турындагы 16.12.2020 ел, №1043 карарына үзгәрешләр кертү турында

Нурлат муниципаль районы башкарма комитетының «Җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2020 елның 17 июнендәге 413 номерлы карары һәм «Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурыч барлыгы (булмау) турында» 2021 елның 27 гыйнварындагы 47 номерлы карары нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең түбәндәге административ регламентларына үзгәрешләр кертергә:

- Муниципаль милектәге җир кишәрлеген торглар үткәрмичә генә арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;
- Аерым максатларда гавами сервитут билгеләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;
- Муниципаль милектәге җир кишәрлеген индивидуаль торак төзелеше өчен гражданнарга милеккә (арендага) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;
- Муниципаль милектәге җир кишәрлеген гражданнарның һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларының милкенә (арендага) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;
- Муниципаль милектәге җир кишәрлеген торак пункт чикләрендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен гражданнарга милеккә (арендага) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;
- Муниципаль милектәге җир кишәрлеген аукцион рәвешендә үткәрелә торган торгларда арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;
- Муниципаль милектәге җир кишәрлеген бакчачылыкны алып бару өчен гражданнарга милеккә (арендага) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;
- Муниципаль милектәге җир кишәрлеген җир кишәрлегендә урнашкан биналар, корылмалар милекчеләренә милеккә яки арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;